**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3044**
**14.06.2019**

Башкарма комитетның «Торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 31 июлендәге 4542 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 31 июлендәге 4542 нче карарына (Башкарма комитетның 2014 елның 11 апрелендәге 2165 нче, 2016 елның 28 июнендәге 3321 нче, 2018 елның 28 апрелендәге 2395 нче, 2018 елның 14 декабрендәге 7501 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән

расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлеге нигезендә»;

2) торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- 1.4 пунктның унынчы абзацын төшереп калдырырга;

- 2.9 пунктның 5 пунктчасында «торак бүлмәне» сүзләрен «күп фатирлы йорттагы бүлмәне» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.5.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап эшен карап тикшерү өчен күп фатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру эшләрен, торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерүне килешенү буенча ведомствоара комиссиягә (алга таба – комиссия) җибәрү.»;

- 5.1 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга: «Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;»;

- 5.1 пунктның 10 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга: «Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин.»;

- 5.2 пунктның икенче абзацында «почта аша» сүзләреннән соң «КФҮ аша,» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет<br>
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин